**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Бирючевка авылы № 16 «11» июнь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2018 елның 08 маендагы 11 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләрне кертү хакында (10.10.2018 №25, от 29.11.2018 №35, от 11.09.2020 №21, от 21.10.2022 №23, от 20.02.2023 №4 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турындагы 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә,

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2018 елның 08 маендагы 11 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары

белән расланган Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә (10.10.2018 №25, от 29.11.2018 №35, от 11.09.2020 №21, от 21.10.2022 №23, от 20.02.2023 №4 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1.1. бүлегенең 1.5 пунктында «12688,00» санын «13323,00» санына алмаштырырга;
2. 3.2 пунктындагы 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны, әлеге карарга кушымта нигезендә, яңа редакциядә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Г.Солтанова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советы карарына кушымта
«11» июнь 2024 № 16

Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә 1 нче номерлы кушымта

## Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге башлыгы, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларның айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Авыл җирлекләрендә | |
|---|---|---|
| | 11 төркем | 12 төркем |
| 1 | 2 | 3 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19 991 | 18 260 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 14 366 | 13 324 |
| Депутатлар | 13 323 | 13 323 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 13 323 | 13 323 |